**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22 АВГ 2014 № 01-02/326

Казан шәһәре

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ
ТЕРКӘЛДЕ
МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ЗАРЕГИСТРИРОВАНО
"05" 09.2014 г.
ТЕРКИ № РЕГИСТРАЦИОННЫЙ 2420

"Иҗтимагый әһәмияттәге мәсьәләләр турында
күмәк фикер алышу һәм җәмәгатьчелек фикерләрен белдерү өчен,
шулай ук башлыча иҗтимагый-сәяси характердагы
актуаль проблемаларга кагылышлы
җәмәгатьчелек фикерен гавами белдерү өчен
Татарстан Республикасы Ютазы районы территориясендә
махсус бирелгән яисә җайлаштырылган бердәм урыннарның
исемлеген раслау турында"
Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының
2013 елның 6 августындагы
№ 01-02/73 боерыгына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең иҗтимагый әһәмияттәге мәсьәләләр турында күмәк фикер алышу һәм җәмәгатьчелек фикерләрен белдерү өчен, шулай ук башлыча иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль проблемаларга кагылышлы җәмәгатьчелек фикерен гавами белдерү өчен Татарстан Республикасы Ютазы районы территориясендә махсус бирелгән яисә җайлаштырылган бердәм урыннарның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы № 01-02/73 боерыгы белән расланган исемлегенә өстәмә турындагы тәкъдимен исәпкә алып,

**Б О Е Р Ы К  Б И Р Ә М:**

1. Иҗтимагый әһәмияттәге мәсьәләләр турында күмәк фикер алышу һәм җәмәгатьчелек фикерләрен белдерү өчен, шулай ук башлыча иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль проблемаларга кагылышлы җәмәгатьчелек фикерен гавами белдерү өчен Татарстан Республикасы Ютазы районы территориясендә махсус бирелгән яисә җайлаштырылган бердәм урыннарның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы № 01-02/73 боерыгы белән расланган исемлегенең 1 нче пунктына, түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «1. | Урыссу ш.т.п. | Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Урыссу ш.т.п., Урыссу ур., 60 | Район мәдәният йорты белән янәшә Урыссу урамындагы 60 нчы йорт янындагы территория |
| | | Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Урыссу ш.т.п., Урыссу, Луговая ур., 62 | «Энергия» стадионы белән янәшә Луговая урамындагы 62 нче йорт янындагы территория». |

2. Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлеге (Слепнева Э.И.) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алырга тиеш.

3. Закон проекты эше бүлеге (Пашкова М.А.) әлеге боерыкның татар теленә тәрҗемәсен тәэмин итәргә тиеш.

4. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге (Сафин А.Г.), Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлеге (Слепнева Э.И.) белән берлектә, әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында (PRAVO.TATARSTAN.RU) рус һәм татар телләрендә урнаштыруны (бастырып чыгаруны) тәэмин итәргә тиеш.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары М.М.Ибәтовка йөкләргә.

Министр Л.Ю.Глухова